Централизованная религиозная организация
Духовное управление мусульман
Российской Федерации

Централизованная мусульманская
религиозная организация
Совет муфтиев России

بسم الله الرحمن الرحيم

**РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ РӘИСЕ,**
**РОССИЯ МӨФТИЛӘР ШУРАСЫ РӘИСЕ**

## МӨФТИ ШӘЕХ
## РАВИЛ ГАЙНЕТДИННЕҢ

## ГЫЙД ӘЛ-ӘДХА — КОРБАН ГАЕТЕ
## МӨНӘСӘБӘТЕ БЕЛӘН

# МӨРӘҖӘГАТЬНАМӘСЕ

**Мәскәү**
Һиҗри белән 1440 елның
10нчы зөлхиҗҗә көне

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

**БИСМИЛЛӘӘҺИР-РАХМӘӘНИР-РАХИИИМ!**

*Рәхмәтле вә Мәрхәмәтле Аллаһ исеме белән башлыйм!*

Җирләрдә вә күкләрдәге барча мәхлүкат олылаган, галәмнәр Хуҗасы, тиңдәше булмаган Аллаһу Сүбханәһү вә Тәгаләгә барча хәмде-сәнәләребез булса иде. Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафага Аллаһының сәламе булса иде. Пәйгамбәребез әһленә, сәхабәләренә, аның пәйгамбәрлегенә ияанып туры юлга баскан һәр мөселман затына Кыямәт көненәчә Аллаһу Тәгалә Үзенең рәхмәтен вә бәрәкәтен бирсә иде!

*Әс-сәләмү аләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү!*

*Барчагызга да Аллаһуның сәламе вә бәрәкәте булсын!*

**Газиз дин кардәшләрем!**

Без бүген мөселман җәдвәлендәге иң олуг көннәрнең берсе — фарыз хаҗ гыйбадәтләренең төгәлләнүенә туры килә торган Гыйд әль-Әдха, ягъни Корбан гаетен каршылыйбыз. Җир шарының төрле кыйтгаларыннан җыелган төрле милләттәге һәм тән төсендәге миллионлаган дин кардәшләребезнең йөрәге Аллаһу Сүбханәһү вә Тәгаләне ярату һәм күтәренке рух белән тулган. Әлеге шатлыклы бәйрәм уңаеннан Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте, Россия мөфтиләр шурасы һәм шәхсән үз исемемнән барыгызны да өммәтебез көтеп алган бөек бәйрәм белән котларга рөхсәт итегез.

Зөлхиҗҗә аеның бу изге көннәрендә хаҗиларыбыз барча галәмнәрнең хуҗасы Аллаһу Тәгалә каршындагы бурычларын үтәделәр, Раббыбыз кушканнарга буйсындылар:

وَلِلّهِ عَلَى النَّاسِ حِجُّ الْبَيْتِ مَنِ اسْتَطَاعَ إِلَيْهِ سَبِيلاً

***«Көче җиткән кешеләргә Аллаһуга гыйбадәт өчен хаҗ кылу фарыз».***
*(3: 97)*

Аллаһу Тәгалә боерган хаҗ гыйбадәте мөселманнарның малларны корбан итеп чалуы белән төгәлләнә.

لَن يَنَالَ اللَّهَ لُحُومُهَا وَلَا دِمَاؤُهَا وَلَكِن يَنَالُهُ التَّقْوَى مِنكُمْ

***«Чалган дөяләрегезнең итләре вә каннары Аллаһуга ирешмәс, ләкин сездән Аллаһуга тәкъвалык вә изге гамәлләр ирешер...»***
*(22: 37)*

Бүгенге бәйрәм көнендә, шушы изге минутларда без һәм фарыз хаҗларын кылучы миллионлаган дин кардәшләребез белән бергәләп Ибраһим

вә Исмәгыйль пәйгамбәрләрнең тормышын, аларның гыйбрәтле язмышларын искә төшереп, бу тарихтан үрнәк алабыз. Бу ике пәйгамбәрнең тормышы сабырлык, Аллаһуга тугрылык үрнәге булуы Каләме-Кәримдә бәян ителә. Раббыбыз Ибраһим аләйһиссәламне сынау рәвешендә төшендә аңа сөекле улын корбан итеп китерү әмерен җиткергәч, ул Аллаһ әмерен үтәмәс өчен сылтаулар эзләп маташмады. Исмәгыйль аләйһиссәламнең дә җавабы сокланута лаек:

﴿قَالَ يَا أَبَتِ افْعَلْ مَا تُؤْمَرُ سَتَجِدُنِي إِنْ شَاءَ اللَّهُ مِنَ الصَّابِرِينَ﴾

***«Ул әйтте: "Әй атам! Үземә әмер кылынганны эшлә. ИншәАллаһ, мине сабыр кылучылардан табарсың"»***
*(37: 102).*

Ибраһим аләйһиссәлам сөекле улын ян ягына яткызып инде корбан итәргә әзер торганда ошбу сүзләрне ишетте:

﴿وَنَادَيْنَاهُ أَنْ يَا إِبْرَاهِيمُ*قَدْ صَدَّقْتَ الرُّؤْيَا إِنَّا كَذَلِكَ نَجْزِي الْمُحْسِنِينَ﴾

***«Без аңа әйттек: "Әй Ибраһим! Син төштә күргәнгә тугры булдың. Тәхкыйк, игелек кылучыларга без тиешлесен кайтарабыз"»***
*(37: 104–105).*

Аллаһу Раббыбыз Ибраһим аләйһиссәламне улын корбан итүдән туктатып, Исмәгыйль аләйһиссәләм урынына терлек малы корбан итәргә боера. Шул рәвешчә ата кешегә һәм улына карата чиксез мәрхәмәтен бирә. Кешелек дөньясы өчен тирән нәсихәт бу.

Шуны беркайчан да исебездән чыгармыйк: мөэмин-мөселман Аллаһу Тәгаләнең сынауларына, авырлыкларга әзер булырга тиеш. Иң кыен вакытларда сабыр итеп яшәргә тиешләр. Ибраһим һәм Исмәгыйль аләйһиссәламнәргә килгән сынауны истә тотып, моннан үзебезгә сабак алырга, нәсихәтләнергә тиешбез. Аллаһу Тәгалә үзенең колларыннан диннәрендә нык торуларын дәлилләп инсаннарны корбан итүләрен сорамый. Киресенчә, җәмгыятькә файда китереп һәм игелекле эшләр башкарып, үзеңнең саулыгыңны, малыңны һәм вакытыңны корбан итү Аллаһу Тәгаләгә ихлас хезмәт итү булып тора. Без Адәм балаларының гомерен сакларга, бер гаепсезгә кеше каны түгелүләрдән, сугышлардан сакланырга тиеш. Кешелек үзара татулыкта һәм хөрмәт итешүдә яшәргә хаклы. Нинди генә проблемалар һәм чикләүләр килеп чыкмасын, без аларны Аллаһы Тәгаләнең рәхим-шәфкатенә буйсынып, чыдамлылык күрсәтеп, сабырлык белән уздырырга тиешбез.

Дин кардәшләрем! Тагын шуңа игътибар итик: тән төсенә, кайсы милләттән булуына, дәрәҗәсенә, матди хәленә аермыйча, дөньяның барча кыйтгаларыннан инсаннарын Аллаһу Сүбханәһү вә Тәгалә изге Мәккә

җирләренә бер гаиләдәй җыеп,
кеше корбаннары кабул ителмәве
фикере тирәсенә берләштергән.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Истә тотыйк, бәйрәм өч көн дәвам итәчәк. Мөселманнарыбызның матур гадәте буенча бу көннәрне бер-беребезне тәбрикләп, туганлык җепләрен яңартып, туганнарыбызны зиярат итеп, аларга бүләкләр өләшеп вә корбан итләреннән сыйлап үткәрик.

Бигрәк тә җәмгыять игътибарына, ярдәмебезгә мохтаҗ фәкыйрь-мескен дин кардәшләребезне онытмыйк. Аллаһы ризалыгын өмет итеп чалынган корбан итләре дә, бәйрәм күчтәнәчләре дә ялгызларга, ятимнәргә, мохтаҗларга барып җитәргә тиеш. Күршеләребезне дә нинди диндә, кайсы милләттән булуларына карамастан, шушы игътибарыбыздан читтә калдырмыйк.

Аллаһының сөекле пәйгамбәре Мөхәммәд саллəллаһу аләйһи вәсәллам әйткән:

أَيَّامُ التَّشْرِيقِ أَيَّامُ أَكْلٍ وَ شُرْبٍ وَ ذِكْرٍ لله تَعَالَى

**«Тәшрикъ көннәре — сыйларны ашау**
**вә эчү вә Аллаһыны зикер кылу көннәредер»**
(Мөслим).

Йөзләгән-меңләгән дин кардәшләребез белән иңгә иң торып бәйрәм намазы укыган хәлдә, корбан итеп чалган малларның итләре белән туганнарыбызны, күршеләрне сыйлаган, фәкыйрь-мескеннәргә өләшкән хәлдә без кешелеккә карата үзара туганлык җепләрен тагын да ныгытабыз, иманыбызны камилләштерәбез.

Олуг Корбан гаете көннәрендә Аллаһуга барлык инсаниятнең, төрле дин вә төрле милләт, төрле фирка әһелләренең үзара кардәшлеген торгыз, аңлашып, татулыкта яшәүләрен бир, фетнә вә сугышлардан арындыр диеп ялварабыз. Я Рабби, күңелләребезне шәфкать-миһербан хисләре белән сугарып, барча кешелеккә тынычлык вә иминлек бир, дип догалар кылабыз!

Я Рабби, риясыз, эчкерсез ният белән башкарган гамәлләребез иманнарыбыз ныгуына, тәкъвалыгыбыз үсүенә сәбәпче булса иде! Я Рабби, корбаннарыбызны кабул кылып, әҗерен чиксез рәхмәтеңнән өләшсә идең! Я Рабби, хаҗ гамәлләрен үтәүче кардәшләребезнең хаҗлары кабул булса иде!

Калебләребезнең түреннән чыккан изге догаларыбызны Ватаныбызның тынычлыгы, иминлеге, тотрыклылыгы өчен ирештерәбез, гаиләләребезгә бәракәтле, сәгадәтле тормыш, авыруларыбызга сихәт, мохтаҗларга дәүләт вә бәрәкәт сорап, галәмнәр хуҗасы Аллаһуга мөрәҗәгать итәбез, вә Аңа гыйбадәт кылабыз.

Гыйд әл-Әдха мөбарәк булсын!

**Мөфти шәех Равил Гайнетдин,**
**Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,**
**Россия мөфтиләр шурасы рәисе**